Azatlıq Radiosı

ЯҢАЛЫКЛАР

# Кушнаренкодагы һөҗүм: мәктәпләрдәге агрессиянең чираттагы очрагымы?

4 сәгать элек




Иллюстратив фото

**Башкортстандагы гимназиядә тугызынчы сыйныф укучысы яшьтәшенә пычак кадаган**

Бүген Башкортстанның Кушнаренко гимназиясендә дәрес вакытында тугызынчы сыйныфта укучыларның берсе икенчесен пычак белән яралаган. Бу хакта беренче булып Башкортстанның премьер-министры урынбасары Урал Килсенбаев хәбәр итте. Зыян күрүчене район хастаханәсенә китергәннәр.

Рәсми затлар үсмернең гомеренә куркыныч юк дип белдерә, әмма зыян күрүченең әнисе сүзләренчә, аңа операция ясалган һәм ул реанимациядә ята. Бу хакта ана кеше "Осторожно, Новости" Телеграм каналына белдергән. Шулай ук ул үсмернең Кушнаренко гимназиясенең кадет сыйныфында укуын әйткән.



Осторожно, новости
Школьнику, которого ранил од...

**Школьника, которого ранил одноклассник в Башкортостане, перевели в реанимацию после операции.**

Мать 15-летнего Д. рассказала «Осторожно, новости», что мальчика прооперировали, сейчас он находится в реанимации. Она добавила, что подросток учился в кадетском классе гимназии в Кушнаренково. По словам матери школьника, с одноклассником, который нанес ножевое ранение, у парня были «нормальные» отношения. О конфликте между одноклассниками женщина не знает.

Очевидцы рассказали «Осторожно, новости», что утром нападавший парень зашел в класс и проигнорировал замечания. Парень встал сзади пострадавшего и после звонка напал на одноклассника.

Также, по информации «Осторожно, новости», 14-летний нападавший нанес Д. несколько ударов в шею с правой стороны кухонным ножом. СК возбудил дело о покушении на убийство

Ана сүзләренчә, аның улының һөҗүм иткән егет белән мөнәсәбәтләре начар булмаган. Ике арадагы ниндидер низаг турында ул ишетмәгән.

Үсмер аның улына беренче дәрестә үк һөҗүм иткән. Каны аккан үсмергә беренче ярдәмне медицина хезмәткәрләре килгәнче укытучы күрсәткән.

Килсенбаев сүзләренчә, башлангыч мәгълуматларга караганда, низагка шәхси каршылыклар сәбәп булган.

Шаһитләр Telegram каналга сөйләвенчә, иртән һөҗүм итүче егет дәрескә соңга калып кергән һәм белдерелгән шелтәне инкарь иткән. Пычак кадаучы сыйныфташы артында басып торган. Шулай ук "Осторожно, новости" язуынча, 14 яшьлек һөҗүм итүче сыйныфташының уң яктан муенына берничә тапкыр кухня пычагы кадаган.

Һөҗүм ясалган егет спорт, аерым алганда самбо белән шөгыльләнгәне әйтелә.

Mash Batash һөҗүм итүче егетнең әтисенә сылтанып язуынча, соңгы дүрт елда аның улын мәктәптә кыерсытканнар.

Тикшерү комитеты үсмергә каршы үтерүгә омтылуда шикләнеп, җинаять эше ачкан.



БУ ТЕМАГА:

Уфада мәктәптә һөҗүм: укучыларны корал алуга нәрсә этәрә?

Уклар башлануга гына карамастан, ике көндә инде өч күңелсез очрак булды. Бүген Яңа Мәскәүдә дә бишенче сыйныфта укучы укытучыны яралаган. Укучының сәламәтлеге белән проблемнары булган диелә. Сакчылар аны туктатып кала алган. Укытучы җиңелчә генә яралар алган.

Кичә, 1 сентябрьдә Красноярски төбәгенең Кански шәһәрендә җиденче сыйныфта укучы кыз укытучыга һөҗүм иткән иде.

Элегрәк психолог Азатлык Радиосына һөҗүмнәр кешеләрдә курку арту белән бәйле дип сөйләгән иде.

"Соңгы еллардагы сәяси репрессияләр, ковид, тотрыксызлык... кешеләрдә курку арта. Хәзер менә һәр йортка кагылачак сугыш. Бу депрессия генә түгел, ә кешеләр арасында психик авырулар, үз-үзенә кул салучыларны арттырачак.

Яшьләр һәм балаларга иң авыры, чөнки аларның киләчәген урладылар. Шуңа балаларга аеруча игътибарлы булу кирәк. Өлкәннәр әзме-күпме тотрыклы

тормышта яшәп калды", дигән иде ул 2022 елны.




йөкләү

🛑 **Русиядә Азатлык Радиосы сайты томаланды, нишләргә? Безнең кулланма.**
🌐 **Безнең Telegram каналына да кушылырга онытмагыз!**

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар саклаган